| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Красноборского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Красный Бор авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.06.2021 Красный Бор авылы № 9-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге Советының 2014 елның 03 июлендәге 35-2 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актны «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 08 июнендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 2014 елның 03 июлендәге 35-2 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 8 пунктындагы 3 пунктчасының 2 нче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт кенәгәсен һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»

1.2. 1 нче кушымтаның 8 пунктындагы 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклар керми»;

2. Әлеге карарны Красный Бор авыл җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (https://agryz.tatarstan.ru) составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе А.Н. Лазарев